**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода, ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе, Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.06.2016 Балык Бистәсе штп. № 105пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында»2016 елның 10 маендагы 67пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә мәктәп каникуллары чорында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруны камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2016 елның 10 маендагы 67пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.«Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнарындагы филиалының Балык Бистәсе бүлегенә (Фәйзуллин и. г.) тәкъдим итәргә:

5.1.үткәрүне тәэмин итәргә:

5.1.1.түләү алмыйча:

- ялны оештыруның гамәлдәге санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килү-килмәүгә санитар-эпидемиологик экспертиза үткәрү;

-балалар сәламәтләндерү оешмаларына, лагерьларның лаборатор-инструменталь тикшеренүләренә, аларны ачар алдыннан гигиеник укыту һәм профилактик медицина тикшерүләре уздыру;

вакытлыча эш белән тәэмин итүне рәсмиләштергәндә балигъ булмаганнарга медицина тикшерүләре уздыру;

- балалар һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларында азык-төлек блокларын дезинфекцияләү ;

- бу объектларда эчәргә яраклы суны анализлау;

5.1.2.төзелгән граждан-хокукый килешүләр нигезендә:

- балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру эше барышында балаларның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өчен лаборатор-инструменталь тикшеренүләр;

5.2. бөер синдромлы геморрагик бизгәкне профилактикалау максатларында сәламәтләндерү оешмалары ачылыр алдыннан дератизация чараларын үткәрүгә белем бирү оешмалары белән килешү төзергә;

5.3.талпан энцефалитын, боррелиозны профилактикалау максатыннан, эшкәртүнең нәтиҗәлелеген тикшереп, акарицидлы эшкәртү үткәрү турында килешү төзергә.»;

1.2.түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14. «Сетевая компания» ААЖ филиалына Балык Бистәсе РЭСының Идел буе электр челтәрләре филиалына (Хәмидуллин Р.Г.) белем бирү оешмалары оештырган җәйге лагерьларга, шулай ук «Сәйлән» стационар лагерена һәм «Өмет» палаткалы лагерена электр энергиясен өзлексез тапшыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.»;

1.3.14-17 пунктларны 15-18 пунктлары дип санарга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2016 елның 10 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин